## Татар дөнья тел күренешендә «милли кием» сегменты[1]

*Җамалетдинов Р.Р., Казан, КФУ, филология фәннәре докторы, профессор,*
*Җамалетдинова Г.Ф., Казан, КФУ, филология фәннәре кандидаты, доцент*

Мәгълүм булганча, когнитив лингвистика кеше һәм кешелек тарафыннан тупланган тәҗрибәне концептуальләштерүгә һәм категорияләштерүгә анализ ясауны, белемнәрне концептуаль төзү һәм тел системасында аларны вербальләштерү ысулларын тасвирлауны максат итеп куя. Телдә кешене чолгап алган реаль чынбарлык, халыкның яшәү шартлары, аның фикерләү һәм чынбарлыкны үзләштерү үзенчәлекләре чагылыш таба. Дөнья тел күренешендә этник менталитет төп концептларда актуальләшә. Аларны өйрәнү милли мәдәниятнең үзәгенә күз салырга ярдәм итә. Тел, мәдәниятнең иң мөһим компоненты буларак, чынбарлыкны үзләштерүнең этник үзенчәлекләрен һәм фикерләү рәвешен гәүдәләндерә.

Һәр дөнья тел күренешенең төп мәдәният концептларына *кеше* концепты керә. Аны анализлаудан башка этносның мәдәниятен тиешенчә тасвирлап булмый, чөнки мәдәният кыйммәтләре системасында теләсә кайсы реалийның урыны – бу реалий артефактлар дөньясына карыймы әллә табигать дөньясынамы, аңа бәйсез рәвештә – иң элек бу реалийга карата кеше уйнаган роль аша билгеләнергә мөмкин. Кеше дөньяны танып-белгәндә, иң элек кешенең дөнья белән үзара бәйләнеше, аның дөньяга «үзенеке» дип катнашуы аңлашыла һәм бары тик шуннан соң гына үзенең дөньядан «үзенеке булган чит» төр буларак аермаларын төшенү башлана. Дөньяда кеше һәм кеше дөньясы арасындагы үзара бәйләнеш – бу «инде алдан билгеләнгән, бер тапкыр формалашкан мәңгелек нәрсә генә түгел, ә һәр мәдәният хәл итә торган бурыч, хаостан галәмне төзү, танып-белүгә һәм төшенүгә бирелүчән дөньяны чиксез мөмкинлекләрдән тәртипкә салынган бербөтен итеп төзү проблемасы да. Телдә теркәлгән самими дөнья күренешен анализлау кешенең аның белән бердәй булуын күрсәтә.

Кеше яшәгән дөнья – Ньютонның «җисемнәр тартмасы» түгел, ә кешенең хәрәкәтчән һәм максатчан зат буларак эшчәнлек итү кыры. Бу эшчәнлек ул кырның пространство сыйфатларына гына кайтып калмый, ә ул сыйфатларны җәмгыять ихтыяҗы һәм аның мөмкинлегеннән чыгып үзгәртеп тә кора. Мәсәлән, татар телендә, гомумән дөньяны атау өчен, *дөнья йорты* дигән гыйбарә бар. Кеше үзләштергән коры җир пространствосы (ойкумена) өзлексез киңәя бара, һәм төрки дөнья күренешендәге «йорт» төшенчәсе туган як һәм бар дөнья төшенчәләре белән янәшә куела.

Кеше дөньясының һәр феномены факт кына түгел, ә артефакт та, ул – үз тәҗрибәсе аша туган һәм кешене билгеле бер мәдәният кодына таянып аңлатырга тырышучы продукт. Әлеге караш буенча, этнос әгъзаларының тормыш-көнкүреше узган пространствоны телдә концептуаль формалаштыру иң әһәмиятле мәдәният семаларын аерып алырга, этносның мәдәният пространствосын төп мәдәният концептларын тасвирлау аша сыйфатларга омтылучы лингвокультурология өчен бик мөһим.

Тел кешенең әйләнә-тирә дөнья турындагы белемнәрен теркәүче һәм тәкъдим итүче төп форма булып тора. Һәр лексик берәмлек чынбарлыкның билгеләнгән фрагменты турындагы берникадәр мәгълүматны туплый. Шуңа нигезләнеп, без реаль чынбарлыкны белемнәребезнең чыганагы һәм аның конкрет бер телдә чагылышы дип карыйбыз.

Татар дөнья тел күренешен билгеләүдә «милли кием» сегменты зур урын алып тора.

Традицион милли костюм матди һәм рухи башлангычларны бергә туплый, шуның белән халык тарихы элементларын, мөһим этномәдәният стереотипларын, этникара бәйләнешләрне һәм дини мөнәсәбәтне чагылдыра.

Милли костюмның төп элементлары электән барлык татарлар өчен дә уртак булган. Татар киеменең милли формалары тирән эчтәлеккә ия (Этнография татарского народа, 2004, 88). Татар хатын-кызларының билләп тегелгән катлы-катлы бөрмәле һәм бала итәкле костюмы – чагыштырмача соңрак чор күренеше. XX гасыр башында фабрика тукымалары чыга башлагач, шәһәр җирләрендә хатын-кызлар киемен Европа модасына ияреп тегә башлыйлар: киемнең өске өлеше гәүдә төзелеше буенча, ә итәкләре күпертмәле, бала итәкле итеп тегелә. Аңа кадәр татар ирләре һәм хатын-кызлары тегелеше белән охшаш киндер яки йон киемнән йөргәннәр, ул озын өлгеле һәм киң булган. Бу монументальлек күкрәккә, кулга, чәчкә куелган яки эленгән бизәнү әйберләре һәм хатын-кызларның катлаулы баш киемнәре белән тагы да көчәйтелгән. Хатын-кыз һәм ир-атлар киемнәренең һәр өлеше телдә номинация процессын узган.

Ислам дине кабул ителгәч, халык киеме мөселманнар өчен уртак традиция кысаларында формалашкан – кием хатын-кыз гәүдәсенә сыланып торырга түгел, киресенчә, аны яшереп торырга тиеш булган. Ә керәшен татарлары киеме башка юнәлештә формалашкан.

Традицион ирләр киеме озын яки кыска чабулы, җиңле булган, аңа төрле рәвештәге якалар беркетелгән. Өлге бердәй рәвешле булып, яшь һәм төс аермалары төсләр, бизәкләр һәм тукыма

[1] Работа поддержана грантом РГНФ № 11-14-16029а/В

сыйфатында гына чагылган. Традицион ирләр киеме – ***күлмәк*** һәм ***ыштан*** – җиңел тукымалардан тегелгән. Күлмәк бик киң булган һәм пута белән бәйләнгән. Казан татарлары утыртма якалы күлмәктән йөрүне мәгъкуль күргәннәр. XIX гасырның икенче яртысында авыш иңсәле, кайтарма якалы күлмәкләр күренә башлый. Моны тикшеренүчеләр фабрика тукымалары чыгу белән бәйләп аңлата (Татары, 2001, 210). Өйдә тукылган *ак күлмәкләр* тамбур яки ука белән чигелә торган була.

Хатын-кызлар киемнәре күптөрлелеге белән аерылып тора; кызлар, яшь яки олы хатыннар киемнәрендә дә аермалар күзәтелә. Эчке кием *күлмәктән, күкрәкчәдән, ыштаннан* гыйбарәт була. Эчке күлмәк өстеннән киң күлмәк киелә.

Өлге үрнәге буенча, хатын-кыз күлмәге ирләрнеке кебек була, әмма ул озынрак тегелә һәм аякны тулысынча каплап тора. Хатын-кызлар киеме тора-бара үзгәреш кичерә һәм төп өлешкә, итәккә бүленә.

Өйдә тукылган ирләр ыштанын, гадәттә, караңгы төскә manылган яки буй-буй тукымадан тегәләр. Туй өчен тегелгән кияү ыштаны өйдә тукылган, бизәкләр төшерелгән киндердән тегелә (Татары, 2001, 272).

Татар киеменең нигезе бары тик вертикаль җөйләрдән тора, горизонталь кисемнәр һәм җөйләр чагыштырмача соңрак күренә башлый (Татары, **2001,** 272).

***Җилән*** – җылы вакытларда киелә торган кечкенә шәл якалы озын киң халат – олы яшьтәге ирләр киеме булган. Аны мәчеткә барганда һәм башка мөһим вакыйгалар уңаеннан кигәннәр. Җиләнне авыр ярым ефәк тукымадан теккәннәр. *Сафиулла дигәне – салынкы гына зур борынлы, өстенә күк постау җилән, башына кара чуклы кызыл фәс кигән, хәлфә сыман кеше* (Ә. Фәйзи). *[Шәкертләрнең] өстендә бер кат җилән, аякларында табансыз читек* (Т.Гыйззәт).

***Чапан*** якасының һәм култык тирәсенең башка төрле булуы белән аерылып торган. Бу – Урта Азия халыкларында киң таралган, халат рәвешендәге киң ирләр киеме (ТЭС, 1999, 643).

Әлеге концепт татар фразеологизмнарында һәм мәкальләрендә бик сирәк очрый: *чапан калыбы* – надан рухани; *яхшы чапан – туй дәүләте* – яхшы кеше, яки тормышта зур байлык. *Чапан* сүзе революциягә кадәрге татарлар һәм руханилар тормышын сурәтләгән матур әдәбият әсәрләрендә бик еш кулланыла. *Яшел чапанның бер җире ямъ-яшел, бер җире кап-кара булып корымлы майга буялган* (Г.Исхакый). *Киштә астында зур кадакта мәрхүм иренең бердәнбер истәлеге – Миңлебай картның төсе уңып беткән чапаны эленеп тора иде* (М. Галәү).

Өлгесе белән ***туры чикмән*** җиләнне хәтерләтә. Ул фабрика поставыннан тегелә. Аны билле кием (камзул, кәзәки) өстеннән кигәннәр, тукыма пута белән бугаannaр. *Иске чикмәнен чуар билбау белән буган киң җилкәле карт, кое улагы янына басып, күк биягә су эчерде* (К. Нәҗми).

***Камзул*** – арткы ягы билләнеп тегелгән, киң, ике якка ачыла торган кыска өс киеме. Аны, тукыма эчлек, бик сирәк кенә мех эчлек куеп, затлы тукымалардан җиңсез яки кыска җиңле (терсәккә кадәр) итеп теккәннәр (ТЭС, 1999, 260).

Камзул күлмәк өстеннән киелгән һәм нигездә өйдә кия торган кием булган, аны урамга чыкканда бик сирәк кигәннәр. *Гайниҗамаллар, машиналы тегүче кертеп, камзуллар тектерә башладылар* (Г. Исхакый). *Өстемә яңа күлмәк кидерделәр, камзулымның төшкән төймәләрен тагып, сүтелгән урыннарын тегеп бирделәр* (Г. Бәширов). – *Үс, энем, үзең тизрәк үс! Яңа камзуллар киеп, кәләпүшеңне кыңгыр салып, озакламый яшьләр уенына үзең төшәрсең* (Г. Бәширов).

Ирләрнекеннән аермалы буларак, хатын-кызлар камзуллары биллерәк итеп тегелгән. Мөселман татар хатын-кызлары камзулны бәйрәм киеме итеп тә кигәннәр. Андый очраклар өчен камзул бәрхеттән һәм ефәктән тегелгән, ука һәм аккош мамыгы белән бизәлгән һ. б. Р. Мөхәммәдова гадәти камзулларда чигешләр күзәтелмәгән дип билгеләп үтә (Мөхәммәдова, 1997, 53). Татар киеменең мөһим атрибутлары арасында ***билбау*** да бар. Татарлар өске киемне генә билбау белән буганнар. Билбаулар кулдан тукылган яки фабрика тукымаларыннан тегелгән, кайбер очракларда йоннан бәйләнгән.

*Ефәк билбау – бил күрке,*
*Матур егет – ил күрке* (М. Фәйзи).

Әлеге концепт фразеологизмнар составында бик сирәк күзәтелә: *Билбау асты бушау* – ашказаны буш; *Билбавы булмаса, эче шартларлык* – артык күп ашаганга ишарә.

Татар туй йолаларында кәләшнең кияү билбавын чишү гадәте яшәгән. Билбау саклау вазифасын үтәгән, аны чишү хатынлык хокукы символына әверелгән (Татары, 2001, 276).

***Түбәтәй*** – баш түбәсенә киелә торган кием. Аны тукымадан теккәннәр һәм сәйлән бөртекләре, ефәк, алтын һәм көмеш җепләр, ялтыравыклар белән чиккәннәр. Парча түбәтәйләр бизәлмәгән. Конус кебек түбәле түбәтәйләрне Кама аръягындагы төбәкләрдә такыя дип йөрткәннәр. *Күлмәк, ыштан, аякчу* белән бергә такыя да кәләш бирнәсендә булырга тиеш дип исәпләнгән. Яшь кияүне законлы никах белән котлап: *«Такыяң котлы булсын!»* – дигәннәр (Мөхәммәдова, 1997, 24).

Түбәтәй эчке баш киеме дип исәпләнгән, аның өстеннән *бүрек,* яки *тула эшләпә* кигәннәр, яки *чалма* ураганнар.

Әлеге концепт фразеологизмнар составында да кулланыла: *Түбәтәй астына җибәргән* – артыгын ашаган яки эчкән; *Түбәтәй* (башка) *тар (әле* монда) – эшләр муеннан.

Ул шулай ук мәкальләрдә дә очрый: *Иске булса да – үз түбәтәем!* – үземнең һәрнәрсәм күңелемә якын һәм яхшы; *Баш түбәтәй өчен түгел, түбәтәй баш өчен* – кайсы нәрсәнең мөһимрәк икәненә ишарә.

*Түбәтәй* концепты матур әдәбият әсәрләрендә дә бик еш очрый. *[Сабирҗан] башындагы түбәтәен төзәтеп кия дә кузгалып уртага чыга* (З. Зәйнуллин). *[Аның] бүрек астыннан каешланып беткән түбәтәй чите күренеп тора* (А. Әхмәт).

Кызлар ***калфагы*** – баш түбәсенә яки маңгай өстенә киелә торган озын итеп тегелгән баш киеме, озын ягы конус формасында яки түгәрәкләп төгәлләнә, аның очына чук беркетелә һәм артка яки янга кайтарып салына. Кызлар калфаклары өстеннән бернәрсә дә ябылмый. Текстларда бу сүз гүзәллек концептына кертелә. *[Вафа] кибеттән бер-бер нәрсә аласың бармы әллә? Кирәк булса, менә бик яхшы калфаклар! Сезнең төсле кызларга матурлык өстенә матурлык китерә!* (Г. Исхакый) *Хәят Пизаларга барырга шул күлмәген киде һәм, дустының киңәше буенча, күлмәге белән бер төстәге кечкенә генә калфагын да прическалы чәчләре арасына кадап куйды. Бу калфак ефәк көлтәсенә чолганган гөл чәчәге (роза) шикелле көлеп тора иде* (Ф. Әмирхан). *Ул аның озын керфекләренең күзене нурландырып торуыны, битенең уртасына аз гына эчкә таба уелып керүене, калфак астында чем-кара чәченең кара урмандагы җансыз күл кеби торуыны карарга тотынды. Аның колагы музыка тавышыны ишетсә дә, күзе шул бикәчтән алынмады.* (Г. Исхакый).

Аяк киеме һәр халык костюмының бер өлешен тәшкил итә. ***Тула оек*** шундыйлар рәтеннән, ул бик борынгы заманнарда ук кулланылган, аны өйдә сугылган ак төстәге постаудан басканнар. *Ул кер шикелле ак тула оек өстеннән өр-яңа җыйнак чабата кигән* (А. Гыйләҗев).

Татар киеменең үзенчәлекле бер элементы бар, ул да булса – ***аякчу*** (аяк чолгавы яки чолгау). Аякчу белән тубыктан өстәрәк балтырларны ураганнар, табаннар аның белән төрелмәгән, шуңа күрә аны портянкалар белән бутарга ярамый. *Хәлим мич куышыннан аякчуларын алып чолгарга торганда, капка әкрен генә, бер дә шыгырдамыйча гына ачылып китте* (Г.Гобәй). *Иртә белән Хәйрулла үзенең чолгауларын алырга кухняга барганда, аңа Гарифә белән Газизә очраганнар* (Ш. Камал).

Аякчуның борынгылыгын *кияү чолгавы* дигән бизәкләп чигелгән яки баш-башлары тукылган йола варианты булу да раслый.

***Читек*** – йомшак күннән (сәхтиян) эшләнгән бер генә төстәге (күбесенчә кара төс) аяк киеме. Өйдән чыкканда, читек өстеннән каты олтанлы күн аяк киеме (кәвеш, ката), ә кышларын сай киез итекләр кигәннәр.

Әлеге концепт татар лингвомәдәниятендә бик еш кулланыла: *Читек майлау (майлашу)* – кул кулны юа; *Читегедер өч тәңкә – чигешедер биш тәңкә* – үзенә күрә түгел, ә артык мактанучы кеше; *Кимә итек, ки читек, читек аяк туңдырмас* – яхшырак күренергә тырыш. *Җиңгәчәйнең өстендә киң итәкле озын кәшемир күлмәк, яшел камзул, башында көмеш тәңкәле тар гына калфак, калфак өстеннән чәчәкле яулык ябынган, юка шәлен иңенә салган, аягында сары читек белән кара галош* (Ә. Еники).

Бүген көнкүрештә традицион татар костюмының аерым элементлары гына күренә: түбәтәйләр, «татарча итеп» яулык бәйләү, сирәк кенә бизәкле татар аяк киемнәре очрый.

Шулай итеп, традицион татар милли киеме халыкның күп гасырлык тарихы дәвамында аның нәфасәти идеалларын гәүдәләндерүче үзенчәлекле тел дә тудыра. Халык киеменең үзенчәлеге – аның этник гомумилек тарафыннан тудырылуында. Халык киеме элементлары, бер-берсе белән форма, төс, фактуралары ягыннан үзара яраклашып, бердәм стиль комплексы барлыкка китерәләр. Милли кием үзендә татар халкының матди һәм рухи мәдәнияте элементларын берләштерә. Алар гүзәллек идеалыннан аерылгысыз. Кием байлык, муллык, милек символлары булып аңлашыла.

Әдәбият


Мухамедова Р.С. Татарская народная одежда. – Казань: татар. кн. Изд-во, 1997.

Татары. – М.: Наука, 2001.

ТЭС – Татар энциклопедик сүзлеге. – Казан: Татар энциклопедиясе ин-ты, 2002.

Этнография татарского народа / Под ред. Д.М.Исхакова. – Казань: Магариф, 2004.